**Татарстан Республикасы**
**Зәй муниципаль районы**
**Сәвәләй авыл җирлеге Советы**

# КАРАРЫ

**№79** **«17» ноябрь 2022 ел**

**"Зәй муниципаль районы Сәвәләй авыл җирлеге башкарма комитетының баш бухгалтеры, муниципаль хезмәт вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш, хезмәте өчен түләүне оештыру һәм түләү шартлары турында нигезләмә хакында" 2019 елның 31 маендагы 203 номерлы Зәй муниципаль районы Сәвәләй авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү турында**

1998 елның 31 июлендәге 145-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә, Зәй муниципаль районы Сәвәләй авыл җирлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Сәвәләй авыл җирлеге Советы

## КАРАР ИТТЕ:

1. "Зәй муниципаль районы Сәвәләй авыл җирлеге башкарма комитетының баш бухгалтеры, муниципаль хезмәт вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш, хезмәте өчен түләүне оештыру һәм түләү шартлары турында нигезләмә хакында" 2019 елның 31 маендагы 203 номерлы Зәй муниципаль районы Сәвәләй авыл җирлеге Советы карары белән расланган (2020 елның 23 сентябрендәге 7 номерлы карар нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) Зәй муниципаль районы Сәвәләй авыл җирлеге башкарма комитетының баш бухгалтеры, муниципаль хезмәт вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш, хезмәтенә түләүне оештыру һәм түләү шартлары турында нигезләмәнең 2.2 пунктына үзгәрешләр кертергә, "Баш бухгалтер" һәм "Бухгалтер" юлларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| Баш бухгалтер | 19 700 сум | 21 000 сум |
| Бухгалтер | - | 18 500 сум |

2. Штат расписаниеләренә һәм локаль актларга тиешле үзгәрешләрне кертергә.

3. Карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Зәй муниципаль районының Сәвәләй авыл җирлеге рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карар 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

5. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

**Совет рәисе** **И.А.Галимов**